РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУСЛЮМОВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
СЕМЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

*423989, Р.Т. Муслюмовский район, с.Семяково, ул.Школьная д.8а*
Sem.Mus@tatar.ru *тел. (8-85556) 3-33-16*
ИНН 1629003953, КПП 162901001, ОГРН 1061687005181, ОКАТО 92242865000.

*Симәк*

*« 20 » 02 2020 ел*

**КАРАР № 5**

Карны вакытлыча урнаштыру урыннарын билгеләү турында

Интенсив кар яву чорында юлларны һәм урамнарны кардан вакытында чистартуны тәэмин итү, Симәк авыл җирлегендә кыш көне территория чистартуны тәртипкә китерү һәм карны вакытлыча урнаштыру урыннарын билгеләү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7 номерлы Федераль закон нигезендә, Симәк авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:


1. 2020 елның кышкы чорында карны вакытлыча урнаштыру өчен ачык мәйданчыклар урыны итеп түбәндәге территорияне билгеләргә:
- Торыш авылында – торак пункттан көнбатыштарак (Октябрь урамыннан 300 метр ераклыкта) (1 нче номерлы кушымта)
- Симәк авылында – торак пункттан көньяк-көнбатыштарак (Симәк-Торыш юлыннан юлыннан 50 метр ераклыкта) (2 нче номерлы кушымта)
- Елгабаш авылында – торак пункттан көнбатыштарак (Колхоз урамыннан 500 метр ераклыкта). (3 нче номерлы кушымта)
- Кызылъяр авылында – Яр – торак пункттан көнчыгыштарак (Мөслим - Сәет юлыннан 150 метр ераклыкта). (4 нче номерлы кушымта)
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны үз өстемә алам.

Симәк авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе

Р.А.Садертдинов

Симәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 20 февралендәге 5 номерлы карарына 1 нче кушымта

# Торыш авылында кар өю урыны



Симәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 20 февралендәге 5 номерлы карарына 2 нче кушымта

# Симәк авылында кар өю урыны



Симәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 20 февралендәге 5 номерлы карарына 3 нче кушымта

# Елгабаш авылында кар өю урыны



Симәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 20 февралендәге 5 номерлы карарына 4 нче кушымта

# Кызылъяр авылында кар өю урыны

